**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КАМСКО-УСТЬИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ КАМА ТАМАГЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

ул. Калинина, д.31,
пгт. Камское Устье, 422820

Калинин урамы, 31 йорт, штп. Кама Тамагы,
422820

тел.: (884377) 2-18-85, факс: 2-20-70,  e-mail: Kamuste.Ispolkom@tatar.ru,  http://kamskoye-ustye.tatarstan.ru.

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2025 енының 21октябре № 577

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының "Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре хисабына укучыларның аерым категорияләрен туклану белән тәэмин итү турында" 2021 елның 22 декабрендәге 1147номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Президентының «Күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм чаралары турында» 2024елның 23 гыйнварындагы 63номерлы Указы, «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012елның 29 декабрендәге 273-ФЗномерлы Федераль законы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында укучыларны тулы канлы туклану белән тәэмин итү максатларында, " Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр " 2.3/2.4.3590-20 номерлы СанПиН таләпләрен үтәү һәм Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль гомуми белем бирү оешмаларында укучыларның аерым категорияләренә социаль ярдәм күрсәтү йөзеннән Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитетының «Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре исәбеннән укучыларның аерым категорияләрен туклandыруны тәэмин итү турында» 2021елның 22 декабрендәге 1147 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 пунктта «10,00 сум күләмендә» сүзләрен «10,70 сум (ун сум,җитмеш тиен ) күләмендә» сүзләренә алмаштырырга;

1.2. 1нче кушымтада:

2нче бүлектәге 2.1нче пунктның өченче абзацында «дүрт» дигән сүзләрне «өч» сүзенә алмаштырырга;

3 бүлегенең 3.4 пунктындагы өченче абзацында « дүрт» сүзләрен " өч» сүзенә алмаштырырга.

Кушымтаның 2 пунктында « дүрт» сүзләрен «өч» кә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

3.Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары Е.В.Сороковнинага йөкләргә.

Җитәкче вазыйфаларын башкаручы Р.Р.Баржанов